**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09,
email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.08.2024 **Чирмешән авылы** № 279

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарны исәпкә алу тәртибе турында һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 14 апрелендәге 176 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексының 57 һәм 95 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 14 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарны исәпкә алу тәртибе турында һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибе турында» 2021 елның 14 апрелендәге 176 номерлы карары белән расланган 8.3 пунктының 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар яисә билгеләнгән тәртиптә бердәнбер торак урыннары яшәү өчен яраксыз дип танылган һәм ремонтланырга яки реконструкцияләнергә тиеш булмаган торак урыннарның милекчеләре булып торучы гражданнарга. Әлеге пунктта күрсәтелгән торак урыннар милекчеләренә социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар чираттан тыш бирелә, әгәр

федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә милек хокукындагы торак урыны урнашкан яисә мондый торак урыны булган күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген киләчәктә мондый торак урынын алу максатларында дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу турында карар кабул ителмәгән булса;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов